Кириллова З.Н.

# КАЗАН АРТЫ КЕРӘШЕННӘРЕНЕҢ ТАБЫН ҖЫРЛАРЫ

Татар халкының милли характерына хас күркәм бер сыйфаты – кунакчыллыгы, дусларча тату яшәүгә, кардәшлек һәм бердәмлек тойгыларына хөрмәте чагылыш алган [1, 23] табын җырлары керәшен татарларының җыр сәнгатендә дә әһәмиятле урын алып тора. Кунак табыны, якыннарны бергә җыйган аш-су мәҗлесе, гаилә бәйрәме яисә туй вакытында туганнар һәм дусларның аралашуы җыр белән үрелеп бара, бу исә мәҗлесне тагын да ямьлерәк һәм кызыклырак итә.

Табында хуҗа һәм кунакларның бер-берсенә матур теләкләр белән җыр әйтешүе һәм күмәк җыр – керәшен татарларының һәр төркеменә дә хас күренеш, ата-бабалардан калган матур традиция. Язмабызда тикшереләчәк табын җырлары Балык Бистәсе районының Казак Чаллысы һәм Иванай авылы керәшеннәреннән тупланды. Әлеге авыллар керәшеннәрнең тел үзенчәлекләрен һәм йола иҗатын төрле яклап өйрәнгән күренекле галимә Ф.С.Баязитова тарафыннан Казан арты сөйләшенең Кама буе урынчылыгына кертелә [2, 11]. Әмма шунысын искәртеп үтү мөһим: керәшен татарларының башка төбәкләрдә яшәүче карендәшләре белән аралашып яшәве, моннан тыш, керәшен җырларының татар халык иҗаты җыентыкларында [1; 3-4] һәм кайбер вакытлы матбугат битләрендә урын алуы нәтиҗәсендә, табын җырларының саны арта, ә аларның билгеле бер төбәккә хас икәнлеген күрсәтүче билгеләре исә югала бара.

Керәшен татарлары мәҗлесләрендә башкарыла торган җырларны эчтәлекләре һәм эзлеклелеге ягыннан берничә төркемгә берләштерергә мөмкин: олылар хөрмәтенә башкарыла торган җырлар, туганнар яки дусларга багышланган җырлар, аш бирү җырлары, тау итү җырлары һәм табынны тәмамлау җырлары. Шуларның һәрберсенә тукталып үтик.

Һәр табын иң элек ***олылар хөрмәтенә җырлау*** белән башланып китә. Әлеге җырлар ярдәмендә мәҗлестә катнашучылар әти-әниләргә һәм, гомумән, өлкәннәргә үзләренең рәхмәтләрен, хөрмәт хисләрен белдерәләр:

Безнең өстәлләргә шул килешә:
Чүпләп кенә суккан ашъяулык.
Ашыйк, ай, әле без, эчиек –
Олылардан калган ашамлык.

Безнең әтекәйнең капкасы
Чыршы-нарат белән тактасы.
Бу ашаганнар, бу эчкәннәр –
Бар да әткәй-әнкәй аркасы.

Безнең әнекәйләребез бик әйбәт,
Әтекәебез кыйбатлы.
Әтекәй ди әнекәй аркасында
Безнең башкынаебыз хөрмәтле һ.б.

Күләме ягыннан иң зур катламны тәшкил итүче икенче төркем – ***туганнар яки дуслар хөрмәтенә башкарыла торган җырлар***. Нигездә хуҗа һәм кунакларның кара-каршы җырлашуы рәвешендә алып барыла, шулай ук кунакларның үзара җыр әйтешүе яки күмәкләшеп җырлау формаларын да алырга мөмкин. Әлеге төркем җырларда күп төрле хис-тойгылар, теләк-омтылышлар чагылыш таба. Мәсәлән, шуларның кайберләре:

- *туганнарны сагыну:* “яндый тәрәзәләрдән күзем алмый сез булдыгыз минем көткәнем”, “быел Мәкәрҗәләргә мин бармадым, сезне бер күрерләргә алҗадым”, “ерак араларны якын итеп, сагынып килдек без күп җирдән” һ.б.:

Агыйделгә бадъян салдым
Тармак-тармак үрергә.
Ике күзем тилмерде инде
Сез туганнарны күрергә.

- *кунаклар килгәнгә шатлану:* “чакырган кунаклар килгәч, безнең күңел булды инде”, “җыен туганнар безгә килгәч, ямьнәр керде

әткәй-әнкәй йортына”, “сез кодалар белән күрешкәчтен, йөзләремә сыймады шатлыгым” һ.б.:

Кырга чыксам, исем китә
Алма агачы иелүләренә.
Үземә үзем хәйран булам
Сезне күргәч сөенүләремә.

- *ярату, якын итү:* “бу җырымны җырлыймын мин җаным сөйгән туганга”, “сезнең өчен минем җаным өзелергә торган җеп кебек”, “илләрдә кеше бикләр күп, сездән башкалары ошамый” һ.б.:

Туганнарым, сезгә ни бирим –
Мәкәрҗәдән килгән малым юк.
Җаным ярып бирер идем –
Җандин башка торыр хәлем юк.

- *туганлыкның кадерен белү, дус-тату яшәү теләге:* “без барыбыз да берләр туган, бер-беребез өчен үлиек”, “юлларга чыксак, юлыбыз уңар, аерылмас туганнар булыек”, “әз гомернең эчләрендә сүз китерешмик берләр беребезгә”, “араларга дошман кертмичә, бергә йөрик гомер эчендә” һ.б.:

Бу дөньялар яралганда,
Кемнәр йөргән аклар өләшеп?
Ашаган бетә, кигән туза,
Утырыйк бергә лә сөйләшеп.

Әлеге төркем җырларда кунаклар яки хуҗа хөрмәтенә бик күп мактау сүзләре әйтелә, аларның төрле сыйфатлары ассызыклана:

- *күркәмлекләре:* “буегыз койган шәм кебек, йөзләрегез тулган ай кебек”, “йөзләреңдә кояш уйный, ай гына куймаганнар”, “мәкнең алсу чәчәге күк күземә күрендегез” һ.б.:

Кара урманнарны өч әйләндем
Кара сусарларның эзеннән.
Карасам, күзем ала алмыйм

Сез туганнарның нурлы йөзеннән.

- *нәселләренең затлылыгы:* “безләр кызыгызны шуңа алдык, нәсел-ырулары затлы дип”, “килгәннән бирле карап торам: сез кайсы пәйгамбәрләрнең нәселе?”, “яхшы ата баласының сүз сөйләшүләреннән билгеле” һ.б.:

Каралты түбәләрем ачылды,
Бастырмалар куйгач басылды.
Килгәннән бирле карап торам:
Сез барыгыз да шушылай асылмы?

- *тәмле телләре:* “йөзләрегездә нурлар уйный, телләрегез җомакай (оҗмах – З.К.) ачкычы”, “шикәрләрдән тәмле, балдан татлы тел тибрәтеп әйткән сүзләрең”, “сезләр белән сөйләшергә җепәкәйдәй тасма тел кирәк” һ.б.:

Агыйделкәйләрнең буена
Балыккайларга сөкә салгансың.
Бу кадәр тәмле сүзләреңне
Умарталар ачып алгансың.

- *өстәлләренең муллыгы, ризыкларының тәмлелеге:* “безнең кодаларның өстәлендә ни ашыйсың килсә, шулар бар”, “безнең туганнарның өстәлендә өч көн ашап-эчсәк тә җитәрлек”, “монда ашаганның, монда эчкәннең гомер буе бетмәс тәмнәре” һ.б.:

Өстемдәге күлмәгемнең
Үтә чыккан зәңгәре.
Аш-суыгыз бигрәк тәмле –
Айсыз бетмәс тәмнәре.

Җыр ярдәмендә мәҗлестә катнашучылар бер-берләренә күп төрле матур теләкләр әйтәләр: “йөргән юлларында яхшы йөре, сокланмаган кеше калмасын”, “бай да булсын, сау да булсын бу ашларның иясе” һ.б.:

Болыннарга чыгам, чәчәк җыям,
Чәчәк белән тула кулларым.

Чәчәк кебек матур булсын иде
Алгы тормышыңда юлларың.

Табын җырларының алдагы төркемен ***аш бирү җырлары*** тәшкил итә. Туй мәҗлесе вакытында алар күбрәк җырлана, чөнки хуҗаларның сыеннан тыш, кодалар һәм хуҗаның якын туганнары үзләренең күчтәнәчләре белән чыгалар, болар исә барысы да җыр белән үрелеп бара:

Олы юлга чыккан идем,
Ак калфаклы кыз килә.
Өстәл өсләрен ямьләндереп,
Ипи белән тоз килә.

Кибетләргә кердем, пәке алдым,
Кисим дип агач башларын.
Аякларга басып, кул чәбәкләп,
Каршы алыйк кодалар ашларын.

Аш бирү вакытында сыйлаучылар һәм кунаклар арасында диалог дәвам итә. Мәсәлән, шуларның кайберләре:

Өй түрендә садыгыз,
Садыгызда – атыгыз.
Бу дәүләтне, бу хөрмәтне
Ничек тартып килде атыгыз?

Ерак безнең кырыбыз,
Күкрәп үскән солылар.
Ник тартмасын безнең атыбыз –
Бәхилләп җибәргән олылар.

Иртә торып тышка чыксам,
Очрады миңа гаетче.
Безнең сыйларыбыз бары шунда,

Сез булмагыз инде гаепче.

Йөгерә-йөгерә җыярларга
Юл буенда юа юк.
Сездә ничек, бездә шулай
Гаеп итә торган йола юк.

Башка мәҗлесләрдә исә аш бирү җырлары берничә дүртюллык белән чикләнә. Шуларны тәкъдим итәбез:

Биек тауның башларында
Әйләнәдер минем башларым.
Тәмле-татлы итеп сез ашагыз –
Сезнең өчен пешергән ашларым.

Өстегезгә кигән алъяпкычның
Алмаларын тигез төшергән.
Безләр киләсене сезләр белгән,
Тәмле-татлы ашлар пешергән.

Алъяпкыч баулары ал тасма,
Бәйли-бәйли торам бит.
Никләр ашамыйсыз, никләр эчмисез –
Каршыгызда җырлап торам бит.

Карлыганнар ашар идем,
Ашасам, тешләрем камаша.
Килгәннән бирле карап торам –
Сезнең аш бирүегез тамаша.

Мәҗлес тәмамланыр алдыннан, ашаган-эчкәнгә рәхмәт әйтеп, ***тау итү җырлары*** башкарыла:

Биек тауның башларында

Ак җәймәләр кордым ау итеп.
Бу җырларны без җырлыйбыз
Ашаган-эчкәнгә тау итеп.

Язлар җитәр, кошлар сайрар,
Ишетер микән Нуриәхмәт.
Ашадык-эчтек, хөрмәт күрдек,
Алла риза булсын, бик рәхмәт.

Иртә торып тышка чыксам,
Ап-ак кырау төшкән шомыртка.
Ашадык-эчтек, хөрмәт күрдек,
Дәүләт иңсен иде бу йортка.

Мичкә лә мичкә балыгыз,
Мәскәүләргә киткән даныгыз.
Мичкәләрдә балыгыз бетмәсен,
Башыгыздан дәүләтләр китмәсен.

Хәзерге җирле сөйләшләрдә һәм йолаларда сакланып калган тау итү сүзе борынгы төрки телдә кулланылган, ә соңга таба ул гарәп теленнән кергән рәхмәт әйтү сүзе белән алмаштырылган [2, 130].

Табын җырларының соңгы төркемен ***мәҗлес тәмамланганда башкарыла торган җырлар*** тәшкил итә:

Урманнардан чыккан чакта
Куак кисеп алдык таякка.
Ашадык-эчтек, хөрмәт күрдек,
Басып карыйк инде аякка.

Челтәр элдем читәнгә,
Җилфер-җилфер итәргә.

Кунаклар йөри китәргә,
Белмим ни хәл итәргә.

Тар гына басмалар булганчы,
Киң генә басмалар булсачы.
Киткән чакларыбыз булганчы,
Килгән чакларыбыз булсачы.

Айкый-чайкый керләр юдым
Кулларым күшеккәнче.
Туганнарым, сау булыгыз,
Яңадан күрешкәнче.

Керәшеннәрнең күп гасырлар дәвамында чарланган һәм һәр мәҗлес өчен дә диярлек уртак булган җырлары гадәттә ике төрле – озын яки кыска көйгә башкарылалар. Озын көйгә җырланучы дүртюллыкларның күпчелеге 10-9, ә кыска көйгә башкарыла торганнары 8-7 шигырь үлчәменә нигезләнә, шулай ук аралаш-катнаш үлчәмнәр дә урын алырга мөмкин. Кайбер кыска үлчәмле җырларның озын көйгә башкарыла торган вариантлары да була, бу мөмкинлек җырга төрле ярдәмлек сүзләр, кушымчалар яки эмоциональ ымлыклар кушу хисабына барлыкка килә.

Керәшен табын җырларының шигъри төзелешенә игътибар итсәк, аларның барысы да диярлек беренче зат исеменнән башкарыла. Әмма җырларда чагылган хис-кичерешләр барлык кешеләр өчен дә уртак һәм аңлаешлы.

Халык җырлары өчен табигый бер күренеш буларак, табын җырларының да зур күпчелегендә төп фикер соңгы ике юлда чагылыш таба. Җырның ике өлеше арасында бернинди мәгънәви бәйләнеш булмаган, ягъни шартлы янәшәлеккә нигезләнеп төзелгән җырлар зур урын алып тора. Мәсәлән:

Алъяпкычыңның чигеше –

Кемнәрдән күчереше?
Тату гына гомер итик
Адәмнәр көлдермиче.

Кызыл-кызыл бөрлегән
Юл буена тезелгән.
Минем кебек кем бар икән
Сезнең өчен өзелгән?

Ләкин шунысына да игътибар итәргә кирәк: беренче карашка, җырдагы тезмәләр арасында бернинди дә мәгънәви бәйләнеш юк кебек тоелса да, кайбер җырларда беренче өлештә тасвирланган күренеш яки образ белән лирик геройның рухи халәте чагыштырыла: алар бер-берсенә охшатыла яки тиңләнә, нәтиҗәдә билгеле бер ассоциатив бәйләнеш, стилистик алымнардан саналган сурәтле янәшәлек барлыкка килә. Мәсәлән, түбәндәге җырларның беренчесендә, турыдан-туры әйтелмәсә дә, ике каенның бер төптән үсүе белән туганнарның бердәмлеге арасында ассоциация туа, икенчесендә исә мыскалларга салып кына, ягъни граммлап кына сатыла торган кыйммәтле ука белән туганнарның затлылыгы арасында тиңдәшлек хасил була:

Кара урманнар уртасында
Ике каен бер төптә.
Сезнең белән утырганнар
Онытылмас бөртек тә.

Ак ука белән сары уканы
Мыскалларга салмыйча сатмыйлар.
Күрер күзгә, сөйләшер телгә
Аерата сезләрне мактыйлар.

Керәшеннәрнең табын җырларындагы шигъри юлларны үзара бәйләп торган образлар, сүз-сурәтләр татар халык җырлары белән уртак. Мәсәлән, иң зур лексик катламны тәшкил иткән табигать күренешләре атамаларыннан

урман, болын, яңгыр, болыт, җил, ай, кояш, йолдыз һ.б сүзләр еш кулланыла. Елга атамаларыннан иң зур урынны Агыйдел алып тора, шулай ук Идел, Мишә, Казанка образлары да очрый. Мәсәлән:

Килә болыт, ява яңгыр,
Китсен иде Мишә буена.
Бу ашаганнар, бу эчкәннәр
Китсен иде гомер буена.

Агач исемнәреннән табын җырларында каен, нарат, шомырт, тал, туйра, алмагач кебек образлар, ә үсемлекләр белән бәйле атамалардан исә гөл, чәчәк, мәк, мадъян (бадъян) һәм каләмпер (канәфер) образлары кулланылыш ешлыклары белән аерылып тора. Мәсәлән:

Каләмпер белән мадъянны
Мыскалларга салмыйча сатмыйлар.
Күрер күзгә, сөйләр сүзгә
Аерата сезне мактыйлар.

Сыйлы табын янында башкарылсалар да, әлеге җырларда ашамлык атамалары сирәк кулланыла, бары аш, ашамлык, ашау, сый кебек сүзләр генә зуррак урын алып тора, аның каравы җыр, җырлау сүзләре исә активлыклары белән аерылып тора. Табын янына җыелуның төп максатын һәм мәҗлестә җырның әһәмиятен түбәндәге юллар да ачык күрсәтә:

Безләр монда ник килдек? –
Ашар-эчәр өчен дип килдек.
Ашаган-эчкән гомер тормый,
Бер күрешер өчен дип килдек.

Җырла дисәң, мин җырлыймын
Берне түгел, бишне дә.
Ашау-эчү арасында
Җырламый килешми дә.

Җидегән йолдыз койрыгы
Борыла микән таңнарга.
Сүздән генә әйтү түгел,
Мөмкин җырдан аңларга.

Йомгак ясап әйткәндә, татар халык иҗатының кыска (дүртюллык), лирик һәм йола җырлары үзенчәлекләрен үзенә туплаган керәшен табын җырлары барлык мәҗлесләрнең дә үзәген тәшкил итеп, кешеләрнең хис-кичерешләрен, теләк-омтылышларын шигъри юллар белән матур көйгә салып белдерү өчен хезмәт иткәннәр. Халыкның авыр тормышын җиңеләйтеп, шатлык-борчуларын җыр-моңга төреп бирергә, туганлык җепләрен тагын да ныгытырга ярдәм иткән әлеге җырлар буыннан буынга тапшырылып, халык хәтерендә сакланып килгәннәр, яңа җырлар исәбенә тагын да байый төшкәннәр. Әмма шунысы кызганыч: хәзерге заманның күп төрле мөмкинлекләре һәм кызу ритмына бирешеп, алар күбрәк олы буын өчен хас булган мираска әверелеп баралар.

**Әдәбият**


1. Татар халык иҗаты. Тарихи һәм лирик җырлар. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1988. – 488 б.
2. Баязитова Ф.С. Керәшеннәр. Тел үзенчәлекләре һәм йола иҗаты / Ф.С.Баязитова. – Казан: Матбугат йорты, 1997. – 248 б.
3. Татар халык иҗаты. Кыска җырлар (дүртюллыклар). – Казан: Тат. кит. нәшр., 1976. – 392 б.
4. Татар халык иҗаты. Йола һәм уен җырлары. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1980. – 319 б.